РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» апреля 2020 ел. г. Альметьевск № 54

Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәрендәге идарәсе (районара) 2020 елның 23 гыйнварындагы ЯФ-08-01 12/361- Дәүләт учреждениесе мөрәҗәгате белән

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 1 нче, № 2 нче кушымталар нигезендә Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә 6 124,86 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләргә.
2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Валеев

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Зак. № 301

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«22» апреля 2020 ел №54
карары белән расланган
1 нче кушымта

Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү буенча
гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 86,77 |
| 2 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 516,70 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 546,35 |
| 4 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 1 975,04 |
| Барлыгы | | 6 124,86 |

Башкарма комитет җитәкчесенең
икътисад буенча урынбасары А.Н. Подовалов

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«22» апреля 2020 ел №541
карары белән расланган
2 нче кушымта

Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү буенча
гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 86,77 |
| 2 | Үлгән кешенең гәүдәсен төрү | 2 061,75 |
| 3 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1 454,96 |
| 4 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 546,35 |
| 5 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 1 975,03 |
| Барлыгы | | 6 124,86 |

Башкарма комитет җитәкчесенең
икътисад буенча урынбасары А.Н. Подовалов